| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Старомензелябашского<br>сельского поселения Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Иске Минзәләбаш авыл җирлеге<br>Советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.06.2024г. № 7

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Совет депутаты И. Ф. Солтановның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 10 өлешендәге 1 пункты, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставының 35 статьясына ярашлы рәвештә, дүртенче чакырылыш Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2024 елның 17 июненнән 6 нчы Кужак бер мандатлы сайлау округы буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы депутаты Солтанов Илфат Фаот улының вафат булуы сәбәпле вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган дип санарга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга (sarmanovo.tatarstan.ru).

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе А.Н.Габдрахманов